**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 9 декабрендәге 4307 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 20 мартындагы 1009 номерлы**
**«Казан шәһәре Башкарма комитетының Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе карамагындагы «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә муниципаль йөкләмәгә кертелмәгән чараларны оештыруга башка субсидия бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78.1 статьясындагы 1 пунктның икенче һәм дүртенче абзацлары, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 22 февралендәге 203 номерлы «Бюджет һәм автоном учреждениеләргә башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен гамәлгә кертә торган норматив хокукый актларга һәм муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләр турында»гы карары нигезендә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 20 мартындагы 1009 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитетының Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе карамагындагы «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә муниципаль йөкләмәгә кертелмәгән чараларны оештыруга башка субсидия бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен раслау турында»гы карарына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 24 сентябрендәге 4025 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарның 4 пунктын түбәндәге редакциядә бирергә:

«4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә»;

1.2. 2.6 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«2.6. Башка субсидия субсидияләр алу һәм алардан файдалану операцияләрен исәпкә алу өчен Учреждение тарафыннан Федераль казначылык органында ачылган шәхси счетка Учреждение түбәндәге чараларны оештыруга муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнары нигезендә төзелгән шартнамәне (муниципаль контрактны) Идарәгә тапшырган көннән алып 10 эш көне эчендә күчерелә:

шартнамә (муниципаль контракт) белән билгеләнгән күләмдә аванс түләүгә;

эшләр башкаруны, хезмәтләр күрсәтүне, товар китерүне раслый торган документлар булганда, шартнамә (муниципаль контракт) буенча башкарылган эшләр, күрсәтелгән хезмәтләр, китерелгән товар өчен түләүгә»;

1.3. кушымтаны түбәндәге эчтәлекле 4.8 пункт белән тулыландырырга:

«4.8. Муниципаль йөкләмәгә кертелмәгән чараларны оештыруга субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүне мониторинглау Идарә тарафыннан Бердәм ведомствоара электрон документ әйләнеше системасында электрон рәвештә формалаштырылган һәм тапшырылган белешмәләр нигезендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгының 2024 елның 27 апрелендәге 53н номерлы әмере белән расланган Юридик затларга, шул исәптән бюджет һәм автоном учреждениеләргә, шәхси эшмәкәрләргә, товарлар җитештерүче, эшләр башкаручы, хезмәтләр күрсәтүче физик затларга субсидияләр, шул исәптән субсидияләр формасында грантлар бирү нәтиҗәләренә ирешүгә мониторинг үткәрү тәртибенә туры китереп уздырыла.

Идарә квартал саен Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсенә Бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасында Россия Федерациясе Финанс министрлыгының 2024 елның 27 апрелендәге 53н номерлы әмере белән расланган Юридик затларга, шул исәптән бюджет һәм автоном учреждениеләргә, шәхси эшмәкәрләргә, товарлар җитештерүче, эшләр башкаручы, хезмәтләр күрсәтүче физик затларга субсидияләр, шул исәптән субсидияләр формасында грантлар бирү нәтиҗәләренә ирешүгә мониторинг үткәрү тәртибенә 4 номерлы кушымта белән билгеләнгән форма буенча, хисап кварталыннан соң килә торган айның 25 нче числосыннан да соңга калмыйча, ә хисап бирелә торган финанс елы өчен – 1 февральдән дә соңга калмыйча, субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүне мониторинглау турында мәгълүмат (алга таба – Мәгълүмат) тапшыра.

Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсе, Идарәдән Мәгълүмат алынганнан соң, 10 эш көне эчендә әлеге мәгълүматны Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) урнаштыра».

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**